*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

МӨСЛИМ ГИМНАЗИЯСЕ

# ТЫЛСЫМ+

№3 (50) Декабрь, 2022 нче ел

Бу санда

*Гимназия сулышы* 2

*Шәфкатьлелек бизи кешене* 2

*Сәләтле балалар* 3

*Укучылар иҗаты* 3

*Куян елы безгә нәрсәләр алып килә?* 4




*Яңа 2023 ел мөбәрәк булсын!!!*

## ХУШ КИЛӘСЕҢ, ЯҢА ЕЛ!

***Хөрмәтле укучылар һәм укытучылар!***



*Менә декабрьнең соңгы көннәренә дә аяк бастык. Тиздән календарьдагы иң күркәм, иң эчкерсез, күңелле бәйрәм - Яңа ел җитә. Әлбәттә инде без - укытучылар һәм укучылар өчен ул күңелле мәшәкатьләр бәйрәме. Чыршы бәйрәмнәре уздырасы, бүләкләр, яңа ел кучтәнәчләре әзерлисе бар. Шул мәшәкатьләр өстенә әле уңышлы гына чирек тәмамлыйсы...*

*Барыгызны да якынлашып килүче Яңа ел белән чын күңелдән котлыйм! Эшегездә, укуыгызда, тормышыгызда зур уңышлар юлдаш булсын! Ходай Тәгалә саулык-сәламәтлектән аермасын, гаиләләребезгә тынычлык бирсен, кайгы-хәсрәт күрсәтмәсен. Яңа Куян елы укытучыларны укучыларының уңышлары белән сөендерсен.*




*Әлеге искиткеч һәм барыбыз да яраткан бәйрәм уңаеннан иң изге теләкләрне кабул итеп алыгыз. Яңа елны, туган һәр яңа көнне елмаеп, зур өметләр һәм хыяллар белән каршы алыгыз! Күңелегез саф, хисләрегез эчкерсез, хыялларыгыз якты һәм матур булсын. Бәйрәмнәрегез мөбәрәк, табыннарыгыз түгәрәк булсын!*

*Яңа елда яңа бәхет яңа ачышлар көтә,*
*Барлык булган борчуларны иске ел алып китә.*
*Бәхетле булыгыз дуслар, кайгы хәсрәт читләсен*
*Елмаюлар йөзегездән мизгелгә дә китмәсен!*

***Мөслим гимназиясе директоры Азат Фәрит улы Мирзаянов***

## БДИ - 2023



Мөслим гимназиясе базасында БДИга әзерлек мәсьәләләре буенча ата-аналар җыелышы булды. БДИ муниципаль координаторы Галимова Л.И. Катнашучыларны БДИ үткәрү кагыйдәләре белән таныштырды. Мәктәп психологлары «Бердәм дәүләт имтиханына әзерлек. Стресска ничек каршы торырга» дигән исем астында чыгыш ясадылар. Гимназиянең 2022 елгы чыгарылыш укучысы, БДИда биология һәм химия фәннәреннән 100 әр балл җыйган Баянов Шамил, хәзерге вакытта Беренче Санкт-Петербург дәүләт медицина университетының беренче курс студенты белән онлайн-әңгәмә оештырылды.

## МӘКТӘП УКУЧЫЛАРЫНЫҢ РЕСПУБЛИКА ҺӘМ БӨТЕНРОССИЯ ОЛИМПИАДАЛАРЫНЫҢ МУНИЦИПАЛЬ ЭТАБЫ КӨНДӘЛЕГЕ




Икенче чиректә укучыларыбыз республика һәм бөтенроссия олимпиадаларының муниципаль этабында катнаштылар. Олимпиадаларның муниципаль этабы тәмамлану алдында тора, бар фәннәрдән дә нәтиҗәләр билгеле булмаса да, уңышлар шактый.

Гимназия укучыларының 31 җиңүе, 175 призлы урыны бар, бу әле соңгы нәтиҗә түгел. Олимпиадалар дәвам итә. Укучыларның күрсәткечләре тагын да артыр дип өметләнәбез.

# ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

## “ЭКОЛИДЕР” КОНКУРСЫ







16 декабрь көнне Казанда “Пирамида” мәдәни-күңел ачу комплексында “ЭКОлидер” республика бәйгесенә йомгак ясалды һәм җиңүчеләр бүләкләнде. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы тарафыннан уздырылучы конкурс нәтиҗәләре буенча «Гомуми белем бирү оешмаларында системалы экологик белем бирү" номинациясендә Мөслим гимназиянең биология укытучысы Ләйсән Бариева хөрмәтләнде.

## СФЕРУМДА ҖИҢҮЧЕ!



Биология укытучысы Бариева Ләйсән Фәхаметдин кызы — «Аралашу марафоны» акциясенең икенче этабында җиңүгә лаек булды. Бу акция укытучыларны VK Мессенджерда коммуникация сервисы - уку профиле белән таныштыруга юнәлдерелгән.

Л.Ф.Бариева РФсенең "Сферум" мәгариф платформасында эш нәтиҗәләре буенча беренче унлыкка керде. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры И.Г.Һадиуллин VK месенджердагы актив эше һәм ТР мәгариф системасында намуслы хезмәте өчен Ләйсән Фәхаметдиновнага Рәхмәт хаты һәм смартфон тапшырды.

## ЕЛ УКЫТУЧЫСЫ

Бөтенрәсәй "Ел укытучысы - 2023" конкурсының муниципаль этабына нәтиҗәләр ясалды.

Бәйгедә катнашучылар дәрес үткәрүнең кызыклы формаларын, укучылар белән эшләүнең нәтиҗәле алымнарын, заманча технологияләрне педагогик эшчәнлектә куллану ысулларын күрсәттеләр.

Мөслим гимназиясенең инглиз теле укытучысы Шәрифуллин Айрат Рәшит улы муниципаль турда лауреат исеменә лаек булды.

## БӨТЕНРӘСӘЙ ХАКАТОНЫ




Мөслим гимназиясе командасын: 6 нчы а сыйныф укучылары һәм команда җитәкчесе - мәгълүматлаштыру буенча директор урынбасары Шәрифуллин Айрат Рәшит улын, РФ Мәгариф министрлыгы һәм ВКонтакте платформасы ярдәмендә, Сферумның «Мәгарифтә коммуникацияләр» Бөтенрәсәй хакатоны финалына әләгүе белән котлыйбыз.

# ШӘФКАТЬЛЕЛЕК БИЗИ КЕШЕНЕ

*Гимназиядә ел саен халыкара инвалидлар көненә багышланган традицион декада уза.*

Бу вакыт эчендә балаларга игелеклелек, шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелек, инвалидларга карата ихтирамлы, кешелекле, игътибарлы караш тәрбияләүгә һәм аларны җәмгыятьнең тулы кыйммәтле әгъзалары буларак тануга юнәлтелгән чаралар үткәрелә.

Халыкара инвалидлар көненә багышланган Игелек атнасы сыйныф сәгатьләре һәм тәрбияви әңгәмәләр үткәрергә мөмкинлек бирә. Шулай ук 1-11 сыйныф укучылары катнашында «Мы вместе! Без бергә!» хәйрия ярминкәсе дә үткәрелә.

Быел да бу ярминкә зур әзерлек белән үтте. Ярминкәгә укучылар пешкән ризыклар, кулдан ясалган әйберләр алып килде.

Шушы декадага өлеш керткән һәр кешегә: сыйныф җитәкчеләренә, укытучыларга, укучыларның әти-әниләренә зур рәхмәт! Ярминкәдән җыелган акча инвалидларга бераз ярдәм булараk тапшырылды.

## ХӘЙРИЯ ЯРМИНКӘСЕ



Халкыбызда элек-электән ятимнәргә, кул-аягы гарипләргә, язмыш кимсеткән кешеләргә хәлләреннән килгәнчә ярдәм итәргә тырышканнар.

Бүгенге авыр заманда шәфкатьле булу бигрәк тә кирәк. Инвалидлар, картлар йортлары күбәю дә, шул турыда чаң суга.

1993 нче елдан декабрь башында Халыкара инвалидлар көнлеге билгеләп үтелә. Әлеге дата белән бәйле рәвештә, безнең Мөслим районында, декабрь башын инвалидлар декадасы итеп үткәрү традициягә керде.

Мин укый торган Мөслим гимназиясе дә хәйрия марафонында катнаша. Һәр класс хәйрия ярминкәләре үткәрә. Без 6 нчы в сыйныфы укучылары да үз өлешебезне керттек. Әниләребез биреп җибәргән тәм-томнарны сатып акча эшләдек.

Аны без, Украинада хәрби бурычын үтәгәндә танкта янган якташыбыз, Петербургта С.М.Киров исемендәге хәрби медицина академиясендә дәвалануы Харрасов Руслан Радик улына тапшырсак дөрес булыр дип уйлыйбыз.

Күбрәк сөендерергә тырышыйк мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрне! Бер-беребезгә игелек һәм изгелекләр кылып яшик!

***Хаҗиева Гүзәл,***
***6 нчы в сыйныфы укучысы***

# СӘЛӘТЛЕ БАЛАЛАР

## Аксаков укулары - 2022



Казанда «Аксаков укулары-2022» фәнни-тикшерену һәм иҗат эшләре буенча XII республика конкурсының финал этабы узды.

Бәйге нәтиҗәләре буенча Мөслим гимназиясе укучылары Регина Басыйрова һәм Адилә Хөсәенова «И слог, и кисть, и звуков чудо...» номинациясендә 3 урынны алды.

Җитәкчеләре рус теле һәм әдәбияты укытучысы Хәйруллина Чулпан Алмазовна.

## Интеллектуаль квест

Мөслим гимназиясе базасында 5-6 нчы сыйныф укучылары өчен математика, физика һәм информатика буенча интеллектуаль квест



узды. Гимназиянең 5-6 нчы сыйныф укучыларыннан торган команда сынатмады. Команда беренче урынга лаек булды һәм беренче дәрәҗә диплом белән бүләкләнде.

## Матбугат битләрендә

“Көмеш кыңгырау” газетасы үткәргән “Дәвам итәбез” бәйгесендә, 3 нче в сыйныфы укучысы Асылъяр Хәсәнова “Шигырь” номинациясендә 1 урынга лаек булды. 51 эш арасыннан Асылъярның язган шигыре иң шәбе дип табылган. Котлыйбыз!

## Christmas is coming




"Мөслим гимназиясе» нең 6, 7, 8 нче сыйныф укучыларыннан торган команда, инглиз теле буенча, Бөгелмә шәһәренең аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче 6 нчы урта гомуми белем мәктәбендә уздырылган, Республика лингвистик конкурсында катнашты. Бәйге «Christmas is coming» исеме астында үтте.

Җитәкчеләре: инглиз теле укытучысы Шәймөхәммәтова Чулпан Разитовна.

# УКУЧЫЛАР ИҖАТЫ



**Миф** ул - хикәяләү, чынбарлыкны фантастик рәвештә гәүдәләндергән «хикәяләр» җыелмасы, дөньяны билгеле бер күзаллау рәвеше.

## Мунчара



Ногманов Фәрһәд, 6в сыйныф укучысы

Борын-борын заманда яшәгән ди, мунчара исемле җәнлек. Ул яшәгән ди иске мунчаларда.

Элеке заманнарда, юынырга теләмәгән балаларны шул мунчара белән куркытканнар ди. Бу җәнлек турында борынгы әби-бабайлар күп имеш-мимешләр уйлап чыгарганнар. Кайбер өлкәннәр дә, үзләренең балаларга сөйләгән сүзләренә ышанып, мунчара килде дип, мунчадан йөгереп кайтканнар, менә шундый хәлләр булган .

***Садриева Раяна,***
***5 нче а сыйныфы укучысы***

## Ай белән кояш



Бик күп еллар элек ай белән кояш иң якын дуслар булганнар. һәм алар икесе дә йолдызларны бик яратканнар. Ләкин йолдызлар кояшны яратмаганнар. Чөнки кояш яктысында алар үзләренең матурлыкларын күрсәтә алмаганнар. Ә ай янында алар матур булып, якты булып җемелдәп утырганнар. Һәм йолдызлар айны үзләреннән җибәрәселәре килмәгән. Кояш моңа бик нык үпкәләгән дә ай белән яңадан күрешмәгән.

***Хатипов Азат,***
***5 нче б сыйныфы укучысы***

***

## Кыз ачуы

Борын-борын заманда яшәгән ди, булган ди бер кыз. Ул бик матур, уңган, булган. Бу кыз өзелеп бер егетне сөйгән. Ләкин ул егет аны яратмаган. Кызның бик ачуы чыккан һәм күҗеле белән теләк теләгән. Егетләр үз парларын таба алмасыннар, бәхетле булмасыннар дип. Шуннан бирле бик күп авылларда яшәүче егетләр ялгыз калганнар. Бүгенге көндә дә өйләнә алмыйча тилмереп яшиләр.

***Садыйкова Әминә,***
***5 нче а сыйныфы укучысы***

***



Борын-борын заманда яшәгән ди ике кыз. Бервакыт кызларның әниләре авырып киткән. Әниләре күпме генә су сораса да, кызлары ишетмәгән. Шулвакыт бу хатын: “И ходаем, кәккүк булыймчы!” – дип сораган. Шул арада кәккүккә әверелеп очып та киткән, шул көннән бирле кәккүкләр балаларын карамыйлар, йомыркаларын чит кошлар оясына салалар икән.

***Нафикова Рената,***
***5а сыйныфы укучысы***

***



Күбәк авылында яшүче Вәли исемле кеше җәй көне кура җиләк җыярга чыгып киткән. Бик озак җиләк җыйганнан соң, кайтырга чыккач, бу кеше адашкан. Күпме генә кайтыр юлын эзләсә дә, кайтыр юлны таба алмаган. Ул шушы тауда мәрхүм булган, шул көннән бирле бу тауны авылдашлары “Вәли тавы” дип йөртәләр.

***Нафикова Регина ,***
***5 нче а сыйныфы укучысы***

## КУЯН ЕЛЫ БЕЗГӘ НӘРСӘЛӘР АЛЫП КИЛӘ?



Бу нисбәттән астрологларның да үз карашлары бар. Алар фикеренчә, йомшак, назлы куян бернинди начарлыклар да алып килә алмый. Нинди генә эшкә тотынсагыз да, чама хисен онытмавыгыз хәерле.

2023 нче ел яңа белемнәр, сәяхәтләр өчен яхшы булачак.

**Кучкар**

Кучкарлар өчен башкалардан аерылып тору 2023 елда аеруча актуаль булачак.

**Үгезбозау**

Үгезбозаулар, сезнең елыгыз бик тыныч үтәчәк. Артык тетрәнүләр көтелми.

**Игезәкләр**

Сезнең өчен салмак кына, кояш нурларында ләззәтләнеп йөри торган вакыт килеп җитте.

**Кысла**

Ай-ай, кыслалар, 2023 ел сезне бераз сынаячак. Йолдызлар сезгә үзегезне кулга алып, иллюзияләргә бирелмичә эшкә тотынырга өнди.

**Арыслан**

Арысланнар, 2023 ел чыннан да сезнеке. Бу елны сездә булган барлык иҗади мөмкинлекләр ачылачак! Тик хис-кичерешләрегез белән саграк булыгыз.

**Кыз**

Кызлар, уйланып эшләнгән эшләр сезне бары тик уңышка илтер.

**Үлчәү**

Авыр чакта сез үзегезнең дә, башкаларның да кәефләрен күтәрә аласыз. Тик шаяруларны бераз үлчәп чамалагыз. Бөтенесе дә сезнең юморны аңламаска мөмкин.

**Чаян**

Чаяннар, 2023 елда сездән дә текә кеше булмаячак. Укуыгызда һәм эшегездә сезне үсеш көтә. Яңа дуслар табачаксыз.

**Укчы**

Киләсе елда сезнең даими рәвешегез - кринж.

**Кәҗәмөгез**

Кәҗәмөгезләр, 2023 ел – сезнең тискәрелегезнең көч җыйган чагы. Тормыш сезне сынап, усаллыгыгызны уятачак.

**Сукояр**

Сукоярлар, укуда һәм эштә уз чираты белән барып, сезгә бернинди авырлык та китермәячәк.

**Балык**

Балыклар, сезгә Куян елының сюрпризларын аңлап бетермичә, бераз җәфаланырга туры киләчәк.

## МОГҖИЗА КӨТКӘНДӘ!











Яңа ел – безнең көтеп алган бәйрәмнәрнең берсе. Яңа ел булгач, яңа тормыш, яңалыклар хакында хыялланасың, максатлар куеп, планнар төзисең.

Ватсаптан скриншот:

***Кыш бабайдан нәрсә сорыйсыз?***

**Аяз:** барлык кешеләргә дә сәламәтлек, байлык.

**Адилә:** сугышлар бетсен иде.

**Артем:** әти-әниемә сәламәтлек сорыйм.

**Айзирә:** тәмле бүләк һәм песи баласы.

**Карина:** матур кофта.

**Милена:** яңа телефон.


*ТЫЛСЫМ+*

Декабрь, 2022 нче ел

***Мөслим гимназиясе укучылары газетасы***

**Баш мөхәррир:** Солтанова Г.М.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.

**Мөхәррир:** Минһәҗева Камилә

**Корректорлар:** Минһәҗева Диләрә

**Корреспондентлар:** Айгельдина Зәринә, Солтанова Алия

**Дизайнер:** Садриев Илназ
**Компьютерда җыючылар:** Латыпов Илназ, Хаертдинов Ранис
**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Тираж**: 100